ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 038 от «25» 02 2021 г.

Муниципаль район башлыгының 2019 елның 20 августындагы 116 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 29 нчы сентябрендәге «2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Комиссиясен төзү турында» 1185 санлы карары нигезендә, Мамадыш муниципаль районы территориясендә 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны әзерләү һәм үткәрү буенча җирле үзидарә органнарының килештерелгән гамәлләрен координацияләү һәм тәэмин итү максатларында, КАРАР БИРӘМ:

1. Муниципаль район башлыгының 2019 елның 20 августындагы 116 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алуны үткәрү комиссиясе турында Нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

- Нигезләмәнең 8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Комиссия карарлары утырышта катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм комиссия утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Комиссия беркетмәсенә рәислек итүче һәм комиссия секретаре карар кабул ителгән көнне кул куя. Тавышлар тигез булганда утырышта рәислек итүче тавыш биргән карар кабул ителгән дип санала.

Мамадыш муниципаль районы башлыгы карарын таләп итүче мәсьәләләр буенча Комиссия тиешле тәкъдимнәр кертә.

- Нигезләмәнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Комиссия рәис, рәис урынбасары, комиссия әгъзаларыннан һәм секретарьдан тора.

Комиссия Рәисе :

1) Комиссия эшенә җитәкчелек итә ,

2) комиссия утырышларында рәислек итә,

000047

3) комиссия эшенең сыйфаты, кабул ителә торган карарларның объективлыгы, эш нәтиҗәләре буенча документларны үз вакытында рәсмиләштерүнең, үз вакытында башкарылуы өчен җавап бирә.

4) Комиссия утырышларын үткәрү датасын һәм вакытын билгели,

Комиссия рәисе урынбасары Комиссия рәисе булмаганда аның функцияләрен башкара.

Комиссия секретаре:

1) комиссия утырышларын үткәрү графигын эшли,

2) комиссия әгъзаларына утырышларны үткәрү вакыты һәм урыны турында хәбәр итә,

3) комиссия утырышы беркетмәсен алып бара һәм рәсмиләштерә.

Комиссия әгъзалары:

1) комиссия эшендә катнашалар,

2) каралган мәсьәлә буенча үз фикерләрен белдерәләр (Бу очракта аерым фикер язма формада),

3) кабул ителгән карарларның компетентлыгы өчен җавап бирәләр,

4) комиссия утырышында җитди сәбәпләр аркасында булу мөмкин булмаганда комиссия секретарен утырышны үткәрү датасына кадәр кимендә ике көн кала кисәтәләр.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Муниципаль районы
Башлыгы А.П. Иванов